# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ ИШЕЕВО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

## КАРАРЫ

21 октябь 2024 ел № 92

**Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының "Ишеево авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Ишеевка авыл җирлеге Советының 2015 елның 03 августындагы 61 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының «Ишеевка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставын Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының гамәлдәге законнарына туры китерү максатларында һәм Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының «Ишеевка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 84-85 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Ишеевка авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Ишеевка авыл җирлеге Советының 2015 елның 3 августындагы 61 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының «Ишеевка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 статьяның 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 39 пунктча өстәргә:

"39) «шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 2003 елның 7 июлендәге 112-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданнар алып бара торган шәхси ярдәмче хуҗалыкларны хуҗалык кенәгәләрендә исәпкә алуны гамәлгә ашыру.»;

2) 18.1 статьяның 5 пунктындагы икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Авыл торак пункты старостасы вәкаләтләре составына әлеге авыл торак пункты кергән җирлек Советы карары буенча, авыл торак пунктындагы гражданнар җыены тәкъдиме буенча, шулай ук әлеге уставның 38 статьясындагы 1 пунктының 1-7 һәм 11 пунктчаларында билгеләнгән очракларда вакытыннан алда туктатыла.»;

3) 38 статьяның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Җирлек Советы депутатының вәкаләтләре вакытыннан алда туктатыла торган очраклары:

1) вафат булган;

2) үз теләге белән отставкага китү;

3) суд тарафыннан хокукка сәләтсез яисә хокукка сәләте чикләнгән дип тану;

4) суд тарафыннан хәбәрсез югалган дип танылса яисә вафат дип игълан ителсә;

5) аңа карата судның гаепләү хөкеме законлы көченә керсә;

6) даими яшәү урынына Россия Федерациясеннән читкә китү;

7) Россия Федерациясе гражданлыгын йә чит дәүләт гражданлыгын туктату - чит ил гражданы җирле үзидарә органнарына сайланырга хокуклы булган Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучының чит дәүләт гражданлыгы (гражданлыгы) йә яшәүгә рөхсәте яисә Россия Федерациясе гражданының йә Россия Федерациясе халыкара шартнамәсе нигезендә җирле үзидарә органнарына сайланырга хокуклы чит ил гражданының чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукын раслый торган башка документы булу, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә башкасы каралмаган булса

8) сайлаучылар тарафыннан чакыртып алынган;

9) җирлек Советы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату;

10) хәрби хезмәткә чакырылу яисә аны алмаштыручы альтернатив граждан хезмәтенә җибәрү;

11) аның чит ил агенты статусын алуы;

12) федераль законнарда билгеләнгән башка очракларда.»;

4) 47 статьяның 1 пунктындагы 1 пунктчасына түбәндәге эчтәлекле бишенче абзац өстәргә::

- «шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 2003 елның 7 июлендәге 112-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданнар алып бара торган шәхси ярдәмче хуҗалыкларны хуҗалык кенәгәләрендә исәпкә ала.».

2. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Ишеевка авыл җирлеге башлыгына «муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәвенә алу турында» 2005 елның 21 июлендәге 97-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә әлеге карарны дәүләт теркәвенә тапшырырга.

3. Әлеге карар дәүләт теркәвенә алынганнан соң рәсми басылып чыгарга (халыкка җиткерелергә) тиеш һәм ул рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән соң )үз көченә керә.).

**Татарстан Республикасы**
**Апас муниципаль районының**
**Ишеево авыл җирлеге башлыгы-**
**Татарстан Республикасы**
**Апас муниципаль районының**
**Ишеево авыл җирлеге Советы Рәисе** Р.Р. Сатдинов